**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**«26» августт 2022 ел** **№ 122**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләрен үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә Нурлат муниципаль районы Советының 05.11.2014 № 329 карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2. Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнарында конкурс нигезендә биләп торучы муниципаль хезмәт вазыйфаларының чираттагы исемлеге билгеләнә:

- муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары;
- муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары»;

1.2. Нигезләмәнең 6 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«6. Конкурс үткәрелми:

1) сайланулы муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләрен үтәүне турыдан-туры тәэмин итү өчен гамәлгә куела торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләгәндә;

2) хезмәт шартнамәсе төзегәндә;

3) җирле үзидарә органы бетерелүгә, аның штаты кыскартылуга (муниципаль хезмәт вазыйфасы кыскартылуга)бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең бүтән вазыйфасына билгеләгәндә;

4) билгеләнгән тәртиптә формалашкан кадрлар резервында торучы муниципаль хезмәткәр (граждан) вазыйфасына билгеләнгәндә;

5) муниципаль хезмәтнең кече, өлкән һәм әйдәп баручы вазыйфаларына билгеләнгәндә».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырырга.

3. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Советының җирле үзидарәгә һәм авыл хуҗалыгына ярдәм буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе А.С. Әхмәтшин